**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2020 елның 3 февралендәге** **4-РС номерлы**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орловка авыл җирлегеннән җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 11 декабрендәге 96-РС номерлы карары белән расланган, үзгәрешләр кертелгән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 61-р номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, кеше тормышының уңайлы шартларына, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатыннан , Лаеш муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орловка авыл җирлегендә, җирдән файдалану буенча һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча, ачык тыңлаулар билгеләргә;

2. Гавами тыңлаулар уздыру чорын билгеләргә - кызыксынучы затларга хәбәр итү мизгеленнән башлап ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылган көнгә кадәр. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы бер айдан ким һәм өч айдан артык була алмый;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетына:

3.1. Әлеге карар үз көченә кергән көннән 14 эш көне эчендә әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы уставында билгеләнгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.2. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән чорда ачык тыңлаулар үткәрергә;

3.3. Гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орловка авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару  кагыйдәләре проектын, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне, йомгаклау карар кабул итү өчен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә.

4. Әлеге  карарны «Кама ягы» газетасында , http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан  Республикасы мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми порталында һәм Интернет-телекоммуникация  челтәренең Лаеш муниципаль районы сайтында:http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И. П. Шитовка йөкләргә.

**Муниципаль район**
**Башлыгы урынбасары** **Т.П.Борһанова**